ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«әлеге Законның $8^1$ статьясындагы беренче өлешенең икенче абзацы нигезендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә гражданнар һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле тәртип кагыйдәләрен билгеләү;

Федераль законның 10 статьясындагы «$а^2$» пунктчасы нигезендә билгеләнгән тәртип кагыйдәләрен үтәү өчен, Татарстан Республикасы территориясендәге гадәттән тыш хәлнең үзенчәлекләрен яисә аның барлыкка килү куркынычын исәпкә алып, Федераль законның 10 статьясындагы «$а^1$» пунктчасы нигезендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә гражданнар һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле өстәмә тәртип кагыйдәләрен, кирәк булган очракта, билгеләү.»;

2) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – егерме өченче абзацларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яисә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләт тапшырылган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге

статьяның беренче өлешендәге егерме дүртенче һәм егерме бишенче абзацларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 11 май
№ 24-ТРЗ